**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зеленая Роща авыл җирлегенең Зеленая Роща торак пунктында гражданнар җыены карары**

2024 елның 23 ноябре № 7

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зеленая Роща авыл җирлегенең Зеленая Роща торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зеленая Роща авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, 2024 елның 23 ноябрендә узган «Сез Лениногорск муниципаль районы Зеленая Роща авыл җирлегенең Зеленая Роща торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлар; мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, контракт хезмәте хәрбиләре һәм аларның гаилә әгъзаларыннан; көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш,, 2025 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Зеленая Роща авылында урамнарны яктыртуга техник хезмәт күрсәтү);

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (Зеленая Роща авылы территориясендә кешеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыра торган карт агачларны кисү; җәйге чорда Зеленая Роща авылы территориясен чабу);

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Зеленая Роща авылы территориясен кардан чистарту; Зеленая Роща авылында Гафиятуллин, Вахитов урамнарындагы чокырларны вак таш белән ремонтлау);

4) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Зеленая Роща авылында эчә торган су үткәргечен ремонтлау һәм төзү)

соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 449 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 233 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 233 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зеленая Роща авыл җирлегенең Зеленая Роща торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Зеленая Роща авыл җирлегенең Зеленая Роща торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. « Сез Лениногорск муниципаль районы Зеленая Роща авыл җирлегенең Зеленая Роща торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлар; мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, контракт хезмәте хәрбиләре һәм аларның гаилә әгъзаларыннан; көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш,ыш, 2025 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Зеленая Роща авылында урамнарны яктыртуга техник хезмәт күрсәтү);

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (Зеленая Роща авылы территориясендә кешеләрнең гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч тудыра торган карт агачларны кисү; җәйге чорда Зеленая Роща авылы территориясен чабу);

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Зеленая Роща авылы территориясен кардан чистарту; Зеленая Роща авылында Гафиятуллин, Вахитов урамнарындагы чокырларны вак таш белән ремонтлау);

4) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Зеленая Роща авылында эчә торган су үткәргечен ремонтлау һәм төзү)

соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң ун көн эчендә түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Зеленая Роща авылы, Төзелеш урамы, 1нче йорт бунча (Мингәрәев исемендәге АКЦ бинасында), Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районының
Зеленая Роща авыл җирлеге башлыгы А.А.Потапов